ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.02.2021 Кошман ав. № 2

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымталарга туры китереп 6424,98 сум күләмендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге»

муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитеты башлыгы Л.Р.Сафина

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның «8» февральнең
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1.Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2756,48 |
| 3.Мәрхүмнең җәсәден (җәсәде калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Кошман авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның «8» февральнең
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 346,53 |
| 3.Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2409,95 |
| 4.Мәрхүмнең җәсәден (җәсәде калдыкларын) зиратка күчерү | 737,94 |
| 5.Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2930,56 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |